40 ШКОЛА

...ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СӘБЫЙЛЫК НУР БЕЛӘН

№6
февраль
2024ЕЛ

# Яшь каләмче

Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе МАОУ “СОШ №40

## Февраль аенда мәктәп ничек яшәде?

## Мәктәп сулышы

Бу санда...15 февраль- совет гаскәрләренең әфган җиреннән чыгарылганына 35 ел!

Бу айда... Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты декадасы үтте

Бу айда...21 февраль- Халыкара туган телләр көне

Бу айда... 23 нче февраль –илне саклаучылар көне

Бу айда... әдәбият, сәнгать өлкәсендәге яңалыклар

Бу айда... укучы иҗаты




*15 февраля 2024 года — 35 лет со дня вывода советских войск из Афганистана. А так же это день памяти о россиянах, исполняющих служебный долг за пределами Отечества. Сегодня мы вспоминаем тех, кто исполняет свой воинский долг за пределами нашей страны, защищая мирных граждан. Это день памяти советских воинов, которые рискуя жизнью, на протяжении долгих 10 лет защищали Афганистан от террористов. Более 14 тысяч солдат не вернулись домой, погибнув при исполнении воинского долга.*





***В музее школы наши учащиеся вспоминали афганские события***

*Әфган сугышы... 15 нче февраль – Россиядә Интернационалист сугышчыларны искә алу көне буларак үткәрелә. Әфган. Илебез тарихының әрнүле, кайгылы бер бите. Күкләргә тиеп утырган таулар арасында үлем белән күзгә –күз очрашкан язмышлар. Меңләгән үлемнәр күргән, меңләгән алданган һәм җимерелгән хыяллар иле. Авыр булса да бу тарих битен хәтер саклыгы белән ел да ача торабыз. Чөнки онытырга һәм оныттырырга ярамый.*

*Әфган - таулар, ташлар иле...*
*Бәгырьләрне өтеп исә сәмум җиле.*
*Кыяларың, бәлки, кемнәргәдер гүзәл.*
*Миңа гүзәл түгел! Түзәм, бары түзәм...*
*Син мине көтмәдең, чакырмадың,беләм.*
*Мин дә үзем түгел, ил кушканга киләм.*
*Боерыкны солдат тикшермичә үтәр...*
*Туган илдә мине газиз әнкәм көтә.*

*Әфган сугышы Бөек Ватан сугышына караганда ике тапкыр озаккарак сузыла.*

*Йөрәктә эзсез үтмәгән 9 ел һәм ике ай – 3338 көн һәм төн дәвам итә сугыш.*

*Таулар илендәге утлы кыялар аша 600 мең совет солдаты һәм офицеры уза. 72-се Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. 15 меңнән артык солдатның гомере өзелә, алты меңе Ватанга кайткач, сугышта алган яра һәм авырулардан вафат була, 311 кеше хәбәрсез югала.*

*1988 елның 15 маенда гына чит илдәге гражданнар сугышыннан совет гаскәрләре чыгарыла башлады һәм ниһаять 1989 елның 15 февралендә соңгы совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыкты.*

# Туган тел декадасы гөрләп үтте

**“Җыр булырлык сүзләр биргән,**
**Туган телем, рәхмәт сиңа!”**

## Атналыктан фоторепортаж

*Мәктәбебездә, традиция буларак, ел саен фән атналыклары үткәрелә. Бу уку елында да атналыклар үтте. Атналыклар кызыклы һәм файдалы чараларга бай булды.*

*7 - 16 нчы февральдә туган тел атналыгы булып узды. Атналык вакытында бик күп класстан тыш чаралар үткәрелде, ачык дәресләр күрсәтелде Бу чараларда төрле милләт укучылары катнашты.*

*“Татар сүзе” дип аталган шигырь бәйрәме, язучы, шагыйрь Фәнис Яруллинга, герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичәләр зур уңыш белән үтте. Укучылар бәйрәмгә бик ныклап әзерләнгәннәр иде. Тамашачы, тын да алмыйча, шагыйрьләребезнең үлемсез шигырьләрен тыңлады..*





















*“Заман” яшьләр үзәгендә*



# Тел дигән дәрья бар...




## 21 нче февраль – Халыкара Туган тел көне

***Туган оясыннан аерылган кош***
***Канатына мәңге ял тапмый.***
***Туган телен яратмаган кеше,***
***Башкаларның телен яратмый.***




## Шәп әйткән!

*...Эзоп, имештер, философ Ксанфның колы булган. Бервакыт Ксанф кунаклар чакырырга уйлаган һәм Эзопка табынга иң яхшы нәрсә пешереп китерергә боерган. Эзоп ит базарына барып тел сатып алган һәм аннан өч төрле ризык хәзерләгән. Ксанф, бу хәлгә гаҗәпләнеп, Эзоптан сораган: –Ни өчен син һаман тел генә китерәсең?- дигән. –Син миңа иң яхшы нәрсә алырга куштың,– дигән Эзоп җавап итеп.- Ә дөньяда телдән дә яхшырак нәрсә бар ?! Тел ярдәмендә шәһәрләр төзелә, халыкларның культурасы үсә. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсе белән аңлашалар, шатлык сөенечләрен уртаклашалар, сөю-мәхәббәт хисләрен белдерәләр. Менә шуңа күрә дә дөньяда телдән дә яхшы бер нәрсә дә юк.*

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***"Язык твой-жизнь твоя, твои мечты, ты без него уже не ты"*** *исемле шәһәркүләм шигырь бәйгесе җиңүчесе* ***Назипова Каринаны*** *һәм аның укытучысы* ***Абдерәшитова Альмира Ходайбирдиновнаны*** *уңышлары белән котлыйбыз!*

*Киләчәктә дә иҗади уңышлар телибез!*



**Туган телем**

Дөньяда иң-иң матур ил,
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел,
Ул – минем туган телем.
"Балам!" - диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
"Әнием!" - дип, әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
"Туган ил" сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган илдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.
*Энҗе Мөэминова*

*С Днем родного языка*
*Я вас поздравляю.*
*Знать, любить его, беречь*
*Людям всем желаю.*

*В языке родном — душа*
*И судьба народа.*
*В нём история его,*
*Вера и свобода.*

*В нём простор родных полей*
*И ручья журчанье.*
*В клятвах слышим мы его*
*И в словах признанья.*

*В колыбельной он звучит,*
*В гимне и сонете.*
*Берегите свой язык,*
*Люди всей планеты.*






***«Халыкара туган тел көне» бәйрәмендә***
















# Укучы иҗаты

# Әдәбият сәнгать өлкәсендәге яңалыклар



## 15 нче февраль-<br>Советлар Союзы Герое,<br>Ленин премиясе лауреаты,<br>"Моабит дәфтәрләре"нең авторы,<br>Герой-шагыйрь<br>Муса Җәлилнең туган көне



*Герой-шагыйрьне искә алып, батырлык дәресләре, сыйныф сәгатьләре, төрле әдәби кичәләр үткәрелде. Укучылар шагыйрьнең үлемсез шигырьләрен сөйләделәр, иҗаты, батырлыгы белән таныштырдылар, китап күргәзмәләре оештырылды.*





## Укучы иҗаты!

**Мусе Джалилю**

*Герой великого народа,*
*Посмертно получивший дань,*
*Твоя жестока несвобода,*
*Момент триумфа свой застань!*

*Ведь нам даже подумать страшно,*
*Какие муки перенес,*
*Проживший жизнь свою отважно…*
*Джалиль нам много преподнес.*

*Мы рады, смелый гений слова,*
*Ваша тетрадь дошла до нас!*
*Нельзя страну лишать такого*
*Творца великих тонких фраз!*

*Гимазетдинова Әминә. 40 нчы мәктәпнең 11 А сыйныф укучысы*




*Шагыйрь Ф.Кәрим 1941 нче елның декабрендә фронтка китә.1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр, ягъни өч ел буена, Фатих Кәрим фронтның алгы сызыгында була, солдат һәм кече офицер, взвод командиры сыйфатында Мәскәү яныннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугышчан юл уза, Украинаны, Белоруссияне, Карпат илләрен азат итүдә катнаша, ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Ә сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була. Күмелгән урыны шундагы Туганнар каберлегендә.*




***"Фатих! Ты жив, жив! Тебя любят, читают и помнят!.."***

*В этом году во многих городах России проходят памятные мероприятия, посвящённые 115-летию со дня рождения известного татарского писателя Фатиха Карима поэта-фронтовика, воина-патриота. Память о Фатихе Кариме чтят во многих уголках нашей страны. "Фатих! Ты жив, жив! Тебя любят, читают и помнят!.." такие слова своей матери, после встреч со студентами и школьниками, повторяла Лейла Фатиховна, дочь поэта.*

*В день гибели поэта-воина Фатиха Карима представители Общества культуры "Кардашлар" совместно с общественностью Багратионовского района 19 февраля провели памятные мероприятия, в ходе которых прошли встречи в музее ДКЦ посёлка Владимирово, посещение места гибели поэта, где установлен памятный камень. На месте гибели (на высоте 37,8 м) в поле, недалеко от дороги, между посёлками Медовое и Садовое (около пос. Владимирово) в 2017 году установили памятный знак – валун с мемориальной плитой и надписью: "Здесь 19 февраля 1945 года погиб в бою командир взвода 226-го сапёрного батальона младший лейтенант Каримов Фатых Валеевич — известный татарский поэт Фатых Карим".*

*На этом месте младший лейтенант Фатих Карим принял свой последний бой.*





*"Яшь каләмче" түгәрәге.Редактор Таҗиева Р.Р.*